**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Баулы муниципаль районы**
**Яңа Зареченск авыл җирлегенең**
**Измайлово авылы торак пунктында**

2025 нче елның 21нче ноябрь № 10

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 һәм 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Яңа Зареченск авыл җирлегенең Измайлов торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Яңа Зареченск авыл җирлегенең Измайлов торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия армиясе сафларындагы хезмәткәрләрдән, свода катнашучылардан тыш, 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә»:

-Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту, җәй көне Измайлов авылында территорияне чабу (МТЗ-82 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган яктырткычлар һәм урамнарны яктырту лампалары, электр товарлары сатып алу, урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр));

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Измайлов авылындагы авыл клубы территориясен карап тоту һәм төзекләндерү).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яна Зареченск авыл җирлеге башлыгы А.Р. Зәбирова